**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4268**
**19.08.2019**

Яр Чаллы шәһәренең «Яр Чаллы»
олимпия резервы спорт мәктәбе»
муниципаль автономияле учреждениесе
тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 17 маддәсендәге 1 бүлекнең 4 пунктчасы, шәһәр Уставының 41, 53, 55 маддәләре, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 нче карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакындагы нигезнамәсенең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 нче карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләр һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе хакындагы нигезнамәсе нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Яр Чаллы» олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                        Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 19 августындагы
4268 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең «Яр Чаллы» олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| Т/с | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе, сумнарда |
|---|---|---|---|
| 1. | Спорт гимнастикасына өйрәтү: | | |
| 1.1. | - балалар; | сум/ай | 1 200,00 |
| 1.2. | - күп балалы гаилә балалары һәм ятим балалар | сум/ай | 840,00 |
| 2. | Балаларны велоспортка өйрәтү | сум/ай | 500,00 |
| 3. | Гимнастика залындагы төркем занятиеләре | сум/сәг. | 1 200,00 |
| 4. | Теннис занятиесе | сум/сәг. | 500,00 |
| 5. | Уен залындагы төркем занятиеләре | сум/сәг. | 1 500,00 |
| 6. | Җиңел атлетика манежындагы төркем занятиеләре | сум/сәг. | 1 500,00 |
| 7. | Җиңел атлетика манежындагы индивидуаль занятие | сум/сәг. | 100,00 |
| 8. | Тренажер залына йөрү | сум/сәг. | 100,00 |
| 9. | Тренажер залына йөрүгә абонемент: | | |
| 9.1. | - балигъ булган бала өчен; | сум/ай | 1 000,00 |
| 9.2. | - студент өчен; | сум/ай | 800,00 |
| 9.3 | - укучы бала өчен. | сум/ай | 700,00 |
| 10. | Тернәкләндерү үзәгенә йөрү | сум/сәг. | 400,00 |
| 11. | Туп һәм ракеткалар (пары) прокаты | сум/сәг. | 150,00 |
| 12. | Вакытлыча яшәү өчен урын бирү: | | |
| 13. | - балигъ булган бала өчен; | сум/тәүл. | 350,00 |
| 14. | - балигъ булмаган бала өчен. | сум/тәүл. | 200,00 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова